ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31 март 2023 ел № 2594

Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 19 октябрендәге 5649 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 19 октябрендәге 5649 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән программаны финанслауны Яр Чаллы шәһәре бюджетында «Гражданнар оборонасы» 03.09, «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгы» 03.10, «Мәктәпкәчә белем бирү» 07.01, «Гомуми белем бирү» 07.02, «Балаларга өстәмә беоем бирү» 07.03, «Яшьләр сәясәте» 07.07, «Мәдәният» 08.01, «Физик культура» 11.01 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына, 2023 елда – 31 217,00 мең сум, 2024 елда – 31 394,14 мең сум, 2025 елда – 31 573,04 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.»;

2) «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасында:

- 1 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 бүлек. Муниципаль программаның паспорты

<table>
<tr><td>Программаның исеме</td><td colspan="5">«2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасы (алга таба – Программа)</td></tr>
<tr><td>Программаны эшләү өчен нигез</td><td colspan="5">«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 69-ФЗ номерлы Федераль закон), «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон</td></tr>
<tr><td>Программаны төп эшләүчеләр</td><td colspan="5">Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе</td></tr>
<tr><td>Программаны үтәүчеләр</td><td colspan="5">Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе</td></tr>
<tr><td>Программаның максаты</td><td colspan="5">Яр Чаллы шәһәре территориясендә янгыннарны кисәтү буенча нәтиҗәле система булдыру</td></tr>
<tr><td>Программаның бурычлары</td><td colspan="5">- Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру;<br>- шәһәрнең гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында, өстәмә белем бирү учреждениеләрендә, яшьләр сәясәте учреждениеләрендә, мәдәният учреждениеләрендә, физик культура һәм спорт учреждениеләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td colspan="5">1 этап – 2023 ел, 2 этап – 2024 ел, 3 этап – 2025 ел.</td></tr>
<tr><td rowspan="7">Еллар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары,</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="4">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2023 (мең сум)</td><td>2024 (мең сум)</td><td>2025 (мең сум)</td><td>Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум)</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>31217,0</td><td>31394,14</td><td>31573,04</td><td>94184,18</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Башка чыганаклар</td><td>-</td><td>-</td><td></td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>31217,0</td><td>31394,14</td><td>31573,04</td><td>94184,18</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре</td><td colspan="5">- янгыннар саны һәм янгыннарда травма алган кешеләр саны кимү;<br>- шәһәрнең гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында, өстәмә белем бирү учреждениеләрендә, яшьләр сәясәте учреждениеләрендә, мәдәният учреждениеләрендә, физик культура һәм спорт учреждениеләрендә янгын куркынычсызлыгын арттыру</td></tr>
<tr><td>Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы</td><td colspan="5">Программа чараларын башкаручы аларның сыйфатлы һәм үз вакытында үтәлүе, бүлеп бирелә торган финанс средстволарыннан рациональ файдалану өчен җаваплы</td></tr>
</table>

- 3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 бүлек. Программаның максаты һәм бурычлары

Программаның максаты булып Яр Чаллы шәһәре территориясендә янгыннарны кисәтү буенча нәтиҗәле система булдыру тора.

Программаның бурычлары булып тора:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру;

2) шәһәрнең гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында, өстәмә белем бирү учреждениеләрендә, яшьләр сәясәте учреждениеләрендә, мәдәният учреждениеләрендә, физик культура һәм спорт учреждениеләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү.

Программаны тормышка ашыруның максатчан күрсәткече булып 2023 ел дәрәҗәсенә карата Яр Чаллы шәһәрендә янгын куркынычсызлыгы торышы тора.

Программаның мөһим максатчан индикаторлары һәм күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

- янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнарның сакланышын арттыру, аларның тискәре нәтиҗәләрен кисәтү һәм җиңеләйтү буенча бурычларны үтәүгә әзерлек дәрәҗәсен саклау;

- муниципаль гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында, өстәмә белем бирү учреждениеләрендә, яшьләр сәясәте учреждениеләрендә, мәдәният учреждениеләрендә, физик культура һәм спорт учреждениеләрендә автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» программа-аппарат комплексы комплекслы адреслы мониторинг системасының техник әзерлек дәрәҗәсен саклау.

Программа чараларын үтәү нәтиҗәсендә социаль һәм икътисадый яктан яраклы янгын куркынычсызлыгы дәрәҗәсенә ирешү, социаль әһәмияткә ия объектларның һәм кешеләр күпләп җыела торган объектларның янгынга каршы сакланышын ныгыту күздә тотыла.»;

- 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

2023-2025 елларга Программаны финанслау күләме 94 184,18 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Программаны тормышка ашыру еллары буенча: 2023 ел – 31217,0 мең сум, 2024 ел – 31394,14 мең сум, 2025 ел – 31573,04 мең сум.

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.»;

- 6 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 бүлек. Программаны тормышка ашыру сроклары.
Программаны тормышка ашыруны контрольдә тоту системасы

Программа 2023-2025 еллар дәвамында гамәлдә.

Программа үтәлешен гомуми контрольдә тотуны Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе гамәлгә ашыра.»;

- 8 бүлекне кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе мөдире Р.К. Шипеевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2023 елның 31 мартындагы
2594 номерлы карарына
кушымта

8 бүлек. Программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм чаралар буенча финанслау

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау, финанслау чыганагын күрсәтеп (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| Максат: Яр Чаллы шәһәре территориясендә янгыннарны кисәтү буенча нәтиҗәле система булдыру | | | | | | | | | | |
| Бурыч: Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | |
| «Янгын сүндерү-коткару отряды» МБУ материаль-техник тәэмин итү | Гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | 2023-2025 еллар | Алдан билгеләнгән бурычларны үтәүгә әзерлек дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 18554,20 | 18731,34 | 19810,24 |
| Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын үтәү | Мәгариф идарәсе | 2023-2025 еллар | Алдан билгеләнгән бурычларны үтәүгә әзерлек дәрәҗәсе, % | 100 | | 100 | 100 | 500,00 | 500,00 | 500,00 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Бурыч: шәһәрнең гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында, өстәмә белем бирү учреждениеләрендә, яшьләр сәясәте учреждениеләрендә, мәдәният учреждениеләрендә, физик культура һәм спорт учреждениеләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү | | | | | | | | | | |
| Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» программа-аппарат комплексы комплекслы адреслы мониторинг системасының техник әзерлеген тәэмин итү | Мәгариф идарәсе | 2023-2025 еллар | Аварияcез эксплуатация дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 4362,00 | 4362,00 | 4362,00 |
| Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» программа-аппарат комплексы комплексы адреслы мониторинг системасының техник әзерлеген тәэмин итү | Мәгариф идарәсе | 2023-2025 еллар | Аварияcез эксплуатация дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 5520,00 | 5520,00 | 5520,00 |
| Өстәмә белем бирү учреждениеләрендә автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» программа-аппарат комплексы комплекслы адреслы мониторинг системасының техник әзерлеген тәэмин итү | Мәгариф идарәсе | 2023-2025 еллар | Аварияcез эксплуатация дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 707,60 | 707,60 | 707,60 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Яшьләр сәясәте учреждениеләрендә автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» программа-аппарат комплексы комплекслы адреслы мониторинг системасының техник әзерлеген тәэмин итү | Яшьләр белән эшләү идарәсе | 2023-2025 еллар | Авариясез эксплуатация дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 290,60 | 290,60 | 290,60 |
| Мәдәният учреждениеләрендә автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» программа-аппарат комплексы комплекслы адреслы мониторинг системасының техник әзерлеген тәэмин итү | Мәдәният идарәсе | 2023-2025 еллар | Авариясез эксплуатация дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 407,40 | 407,40 | 407,40 |
| Физик культура һәм спорт учреждениеләрендә автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» программа-аппарат комплексы комплекслы адреслы мониторинг системасының техник әзерлеген тәэмин итү | Физик культура һәм спорт идарәсе | 2023-2025 еллар | Авариясез эксплуатация дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 875,20 | 875,20 | 875,20 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Гомуми белем бирү оешмаларында укучылар арасында «Куркынычсызлык мәктәбе» республика слёт-ярышында катнашу | Мәгариф идарәсе | 2023-2025 еллар | Чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| Укучылар арасында янгынга каршы тематикага иң яхшы инша, иң яхшы рәсем һәм гамәли иҗат өлкәсендә иң яхшы эш конкурсында катнашу | Мәгариф идарәсе | 2023-2025 еллар | Чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| барлыгы: | | | | | | | | 31217,00 | 31394,14 | 31573,04 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева